# Милли үзаң тәрбияләүдә массакүләм мәгълүмат чаралары

*Сәлимгәрәев А.С.,*

*«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе*

Хөрмәтле Марат Готыф улы, коллегалар!

Бүгенге яшәештә массакүләм мәгълүмат чараларының әһәмияте әйтеп бетергесез. Милли матбугаттан башка туган телебезнең үсешен күз алдына китерү мөмкин түгел. Әгәр милли мәгълүмат чаралары юкка чыга башлый икән, димәк милләтнең киләчәге дә шик уята.

Игътибар итегез: татар матбугатымилли сәясәтне яктырту белән генә чикләнми, ә аны тормышка ашыруда актив катнаша, милли чараларны оештыра, милләтбалаларын бергә туплый, аларны рухландыра.

Татарстан - милли матбугат традицияләрен саклаучы төбәкләрнең берсе. Бүген республикада татар телендә иҗат итә торган 334 массакүләм мәгълүмат чарасы теркәлгән. Шул исәптән 39 телеканал һәм телепрограмма, 35 радиоканал һәм радиопрограмма, 156 басма матбугат,99 электрон басма, 5 мәгълүмат агентлыгы.

Халкыбызның рухи мирасы булырдай газета-журналларыбыз бар. Аларбер гасыр дәвамындахалыкка хезмәт итәләр: «Ватаным Татарстан» (104 ел), «Татарстан яшьләре»(102 ел), «Татарстан» журналы(102 ел), «Казан утлары»(100 ел), «Чаян» (99 ел), «Ялкын» (98 ел), «Сабантуй»(98 ел), «Сөембикә»(96 ел). Мондый бай тарихлы матбугатка ия халыкларкүп түгел. Электрон ресурсларны үстерүгә игътибар кирәк, ләкин басма матбугатны почта тартмаларыннан алып укырга теләүчеләр турында да онытмасак иде. Социологик тикшерүләр күрсәткәнчә, халыкның өчтән бере китап-журналларны басма вариантта үз итә.

Милли матбугатның ролен тирәнтен аңлаган өчен, аның үсешенә керткән саллы ярдәме өчен Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенә зур рәхмәтемне белдерәсем килә!

Комиссия ярдәме белән чыннан да күп кенә проектлар гамәлгә ашырыла. Аның инициативасы белән вакытлы матбугатка язылуны оештыру өчен Республика бюджетыннан инде ике ел буезур күләмдә акчалар бүлеп бирелә. Басма чараларга республиканың барлык мәктәпләре, шулай ук мәдәният, сәламәтлек саклау, социаль яклау оешмалары яздырылды. Ике ел эчендә 101 070 данә вакытлы матбугат чарасына яздырылды, алар арасында 17 республика һәм 8 зур шәһәр һәм район басмалары бар.

Коммиссия ярдәме белән оештырылган бүтән проектлар белән дә горурланабыз. Мәсәлән,

- «Татарстан» телерадиокомпаниясе «Мин этине өйрәтәм» дип исемләнгән юмористик радиосериал әзерләде;
- «Сөембикә» журналы «Татар гаиләсе – үрнәк алыгыз» проектын гамәлгә ашырды.Бәйге барышында редакция тарафыннан ай саен республикабызның төрле районнарында яшәүче гаиләләр турында язмалар әзерләнде. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында бәйгедә катнашкан гаиләләрнең фотоларыннан күргәзмә оештырылды;
- «Шәһри Казан» газетасы «Татарча беләм» дигән махсус сәхифә эшләде. Бу сәхифәдә укучылар татар телендә сөйләшергә өйрәнгән башка милләт вәкилләре белән таныштылар.

- «Ватаным Татарстан» газетасы битләрендә– «Бөекләр эзеннән», «Татарча сөйләшәбез», «Бергә җыелганда», «Мин – татар», «Миллият», «И, туган тел» проектлары;
- «Идел» журналында– «Тайм-аут», «Фәнни LAB» «Кыямовлар кыздыра», «Яңа дулкын»,«Казан – куллану инструкциясе», «Мин авылда калам», «Әдәби портрет» һәм башка проектлар.
- «Ялкын» журналында– «Шәп лейбл», «Әйдә киттек!», «Туфан», «Казаныш», «Мин/без Татарстан», «БуынБатл», «Сораштыру», «Әтәлим-шоу» проектлары.
- «Салават күпере» журналында«Беләсем килә», «Бәби сүз», «Күңелле әлифба», «СалаваTik» проектлары.

Комиссия ярдәме белән тормышка ашырылган проектларның бу әле берничәсе генә. Алар шактый. Һәр проектның асылына төшенеп, ярдәм оештырган өчен, Комиссия рәисе Марат Готыф улы Сезгә, шулай ук Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты җитәкчесе Айрат Ринат улы Зариповка татар матбугаты әһелләре исеменнән ихлас рәхмәтләремне җиткерәм.

Бөтенроссия халык санын алуга әзерләнү, милләттәшләребезне бергә туплау максатыннан күләмле эш алып бардык. Халкыбызның мәнфәгатьләрен якларга читтә эшләп килгән татар мәгълүмат чаралары да ярдәм итә. Россиянең18 төбәгендә 30 газета, журнал, теле- һәм радио тапшырулар татар телендә чыга. Әлеге редакцияләр миллитормышны, Татарстанның көнүзәк темаларын даими рәвештә яктырта; бөтен Россиядә татарларны берләштерүгәүз өлешләрен кертәләр.Илнең 14 төбәгендә газетада кушымта булып «Без бергә» кушымтасы чыга. Ул

“ТАТМЕДИА” җәмгыяте тарафыннан әзерләнә. Ай саен 70 меңнән артык гомуми тираж белән чит төбәкләрдә таратыла.

Шунысын ассызыклап үтәргә кирәк: бөтен заманча таләпләргә җавап бирә торган милли матбугат рус мәгълүмат чараларыннан ким түгел. Әйтик, хәзерге вакытта LiveInternet сайтлар рейтингының беренче баскычларында«Интертат», «Татар-информ», «Яңа гасыр», «Шәһри Казан», “Ватаным Татарстан”, “Сөембикә”кебектатар телле сайтларныда таба алабыз. Бу татар телле матбугатка игътибар һәм,иң мөһиме, аларның киләчәге барлыгын раслый.

2021 елның декабрендә Татарстанда«Яңа гасыр» телеканалы телекарау күләме буенча «Беренче канал»белән алдынгы урынны бүлеште. Телеканал эфириндататар телендә чыгып килүче күңел ачу программалары, канал үзе төшергән яисә татарчага тәрҗемә ителгән телесериаллар барганда, рейтинглар аеручы югары. Нәкъ менә җирле продукциябезнең тамашачыга якын, аңа туган телдәге сөйләм тансык. Димәк, югары рейтинглар булсын өчен, редакцияләр милли тапшыруларныбулдыру өстендә эшләргә тиеш. Киләчәктә «Яңа гасыр» татарча сериаллар төшерүне дәвам итәчәк.

Бездә милли мәдәникыйммәтләрне саклап калу һәм таныту максаты белән эшләүче уникаль радиостанцияләребезбар. Милли көйләрне тамашачыга җиткерүче «Татарстан авазы»интернет-радиостанциясенең аудиториясе үсә.Классик әсәрләр белән беррәттән заманча сыйфатлы көйләрянгыраткан «Тәртип» радиосы Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов ярдәме белән яңарыш кичерде.

Яр Чаллы шәһәреннән республика районнарына турыдан-туры эфирда тапшырулар алып баручы «Күңел» радиосына заманча җиһазлар куелды.

Бары тик бездә генә матур әдәбият әсәрләрен халыкка җиткерүче «Китап» радиосы бар.Аны хәзер Яндекс-колонкалар аша да тыңларга мөмкин. Республика Президенты ярдәме белән Татарстан китап нәшрияты тормышка ашырган аудикитаплар проекты хәзер “Китап” радиосына да хезмәт итә.2018 елдан алып барлыгы 770 сәгать аудиоязма әзерләнгән иде.“Татар әдәбияты үзәге” сайтында исә барлыгы2100 электрон китапурнаштырылган.

Милли үзаңны тәрбияләүгә рус телендәге медиапроектлар да зур өлеш кертә. Мәсәлән, Халык санын исәпкә алу алдыннан оештырылган “Миллиард.татар” проекты әнә шундыйлардан. Ул тарихчыларны, җәмәгать эшлеклеләрен, журналистларны бер мәйданга туплады, милли сәясәткә бәйле кискен дискуссияләр кузгатты. «Хатлар йорты» проекты белән берлектә «Миллиард.татар» сайтында махсус бит булдырылган иде, аннан Җир шарының төрле почмакларына татарча открытка җибәрергә мөмкин.

Бер ел элек, «ТАТМЕДИА» АҖ  ярдәме белән, «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясе булдырылган иде, заманча интерактив кесә китаплары чыга башлады. Бүген инде икешәр мең тираж белән 10 китап чыкты. Алар башка татар матбугаты кебек үкOzon, Wildberries, KazanExpress, Яндекс. Маркет кебек барлык маркетплейсларда сатыла. Башкортстанның сәүдә челтәрләре һәм почта бүлекчәләре белән дә хезмәттәшлек башланды.

Бүген яңалыкларны социаль челтәрләрдән уку тенденциясе киң таралган.Татар телле матбугат чараларының социаль челтәрләрендә

барлыгы 170тән артык аккаунты, мессенджерларда 25 каналы бар. Аларга язылучылар саны барлыгы миллон ярымны тәшкил итә.

Милли мәгълүмат чараларын югарыбелемле,заманча фикер йөртә торган журналистлардан башка үстереп булмый. Медиада эшләргә теләк белдерүче, туган телне яхшы белүче яшьләрне ачыклау максатыннан редакцияләр югары һөнәри уку йортлары беләнхезмәттәшлек итә. “ТАТМЕДИА” акционерлар җәмгыяте каршында Журналистика мәктәбе оештырылды. Татар журналистикасында белгечләр үстерүдә Казан федераль университетының Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбе үз өлешен кертә. Ләкин татар телендәге юнәлеш буенча бюджет урыннарының саны 7әү генә. Республикабыз Президенты йөкләмәсе нигезендә 2018 һәм 2019 елларда барлыгы 16 студент институтка урнаштырылып, республиканың массакүләм мәгълүмат чараларының редакцияләренә беркетелде.Быел әлеге проектның беренче карлыгачлары татар редакцияләренә эшкә урнашачак.

Шулай ук, Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты татар массакүләм мәгълүмат чаралары өчен бюджет хисабына журналистлар әзерли башлады. Булачак журналистлар «ТАТМЕДИА» газета һәм журналлары редакцияләрендә практика уза, моннан тыш, бу редакцияләрнең җитәкчеләре үзләре дә студентлар белән дәресләр һәм очрашулар үткәрә. 2022 елда биредә 21 студент, 2023 тә - 20 студент диплом алачак.

Яшь буында уку культурасын тәрбияләү –милли матбугат чараларының киләчәк аудиториясен үстерү дигән сүз. Моның өчен балалар һәм яшьләр журналларына заманча платформаларныактив үзләштерергә туры килә. Татарстан Президенты каршындагы Татар телен

саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән гамәлгә ашырылган «Татмедиа Junior»проектыинтернетта заманча эшләүнең уңышлы үрнәге булып тора. Контент социаль челтәрләрдә урнаштырыла, офлайн-чаралар һәм укулар оештырыла.

2021 елның августында «ШАЯН ТВ»ның «Тик Ток» фабрикасы эшли башлады, аның максаты шулай ук балаларга татар телен өйрәтү һәм милли мәдәнияткә җәлеп итү.

***

Милли мәгариф, милли мәдәният, милли матбугат, туган тел бер максатка хезмәт итә. Әлеге чылбыр бер урында өзелә икән, барысы да муенса мәрҗәннәре кебек таралып югалачак. Мәктәп, редакцияләр, сәнгать әһелләре, яшьләр оешмалары – барыбыз да аркага арка куеп эшләргә тиешбез.

Безнең төп бурычыбыз - бүгенге көн укучысында милли үзаң тәрбияләү, социаль актив шәхес үстерү, татар халкының рухи кыйммәтләрен саклап калу. Массакүләм мәгълүмат чаралары, традицияләрне саклап, яңа технологияләрне кулланып, милләтебез мәнфәгатьләрен яклап, актив эш алып барачак.